СОВЕТ
БОЛЬШЕКУРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ КАРАУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Большие **КАРАР**

**5.12.2024** Кургузи **№ 190**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәт хакы күләмен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында»гы 25.09.2020 №4 карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (Советның 23.09.2022 №82, 30.12.2022 №102, 18.06.2024 №172 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «28.03.2018 ел, № 182 карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары нигезендә Олы Карауҗа авыл җирлеге Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәтенә түләү күләмнәрен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында»гы 25.09.2020 елның 4 номерлы карарына (Советның Советның 23.09.2022 №82, 30.12.2022 №102, 18.06.2024 №172 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба-карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
1). 1 пунктта:
1.1) беренче абзацта «2024 елның 1 июленнән» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнварыннан»сүзләренә алмаштырырга.;
1.2) икенче абзацта «18 260 (унсигез мең ике йөз алтмыш) сум күләмендә һәм 19 569 (унтугыз мең биш йөз алтмыш тугыз) сум күләмендә айлык акчалата бүләкләү» сүзләрен «19 173 (унтугыз мең йөз җитмеш өч) сум күләмендә һәм айлык акчалата бүләкләү 20 548 (егерме мең биш йөз кырык сигез) сум күләмендә» сүзләре белән алмаштырырга;
2). 2 пунктта:

2.1) беренче абзацта «2024 елның 1 июленнән» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнварыннан»сүзләренә алмаштырырга;
2.2) икенче абзацта «18 260 (унсигез мең ике йөз алтмыш) сум күләмендә» сүзләрен «19 173 (унтугыз мең йөз җитмеш өч) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга»;
3) 3 пунктта «2024 елның 1 июленнән» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнварыннан»сүзләренә алмаштырырга.;
4) "Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Карауҗа авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының 2024 елнын 5 декабрендагы №190 карарына Кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "ОЛЫ КАРАУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ХЕЗМӘТ ХАКЫ КУЛЭМЕ

| **Муниципаль хезмәт вазыйфаларының атамалары** | **Айлык күләме вазифа хезмәт хакы, сум** |
|---|---|
| Олы Карауҗа авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркатибе) | 18 607 |
| Әйдәп баручы белгеч | 15 529 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Зур Карауҗа авылы, Күпер урамы, 23 йорт(мәдәният йорты бинасы), Зур Күлбаш авылы, Тау асты урамы, 26 йорт (мәдәният йорты бинасы) адресы буенча урнаштырырга.

**Олы Карауҗа авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **И.С. Камалиев**